ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.11.2024 г.Мензелинск № 340

**«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2025 елга «Муниципаль берәмлекнең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 14.12.2009 ел № 854 карары һәм «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2025 елга расларга:

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,75 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

2. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А. Г. Гатинага йөкләргә.

**Җитәкче** **М.Р.Кәримов**

Расланган
«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты житәкчесе карары белән
«29» 10 2024 № 341

# НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР
## «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | бишьеллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 78 737 | 89 952 | 115 527 |
| **Сынлы сәнгать** | **шәһәр җирлеге** | | **41 684** | | **37 010** | **88 817** |
| **Хореографик сәнгать** | **шәһәр җирлеге** | | | **87 814** | **72 312** | **265 068** |
| **Гомуми эстетик сәнгать** | **шәһәр җирлеге** | | | **36 926** | | |
| **Фольклор сәнгате** | **шәһәр җирлеге** | | | **80 741** | **77 524** | **124 555** |
| **Эстрада-джаз сәнгате** | **шәһәр җирлеге** | **121 586** | | **116 554** | | **191 128** |
| **Театр сәнгате** | **шәһәр җирлеге** | **62 682** | | **58 352** | **58 267** | **87 898** |